# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушма авыл җирлеге составына керүче Түбән Ушма торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында

№ 2 20 октябрь 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегенең Түбән Ушма торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Түбән Ушмы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылыр хәм аларнын гаилә агъзәләре,күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә сез ризамы

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Түбән Ушмы торак пунктында юлга вак таш җәю: (материал сатып алу, вак таш,ком җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Түбән Ушмы торак пунктында урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру яки алыштыру;

- Түбән Ушмы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

- Түбән Ушма торак пунктында зират коймасын алыштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Түбән Ушма торак пунктында Совет урамында җәяүлеләр күпере төзү (материал сатып алу,килешү буенча эш өчен түләү)

3. Әлеге карарны Түбән Ушма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушма авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.М. Ганиев